**Дүртенче чакырылыш**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 108-12 «14» декабрь 2021 ел

Азнакай муниципаль районы җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләренә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән Азнакай муниципаль районы Советының 2015 елның 19 мартындагы 347-51 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибе нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләре Советларына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

**торак мөнәсәбәтләре:**

- Татарстан Республикасы муниципаль районының махсуслаштырылган торак фонды составыннан торак урыннарны кертү һәм төшереп калдыру;

- социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү;

- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү;

- муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт урыны наймы шартнамәләре буенча торак урыннары бирү;

- элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин